ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2025 елда Татарстан Республикасында партнерлык финанславы экспериментын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре. 2026 елга планнар һәм бурычлар

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры М.Р. Шаһиәхмәтовның «2025 елда Татарстан Республикасында партнерлык финанславы экспериментын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре. 2026 елга планнар һәм бурычлар» мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2025 елда Татарстан Республикасында партнерлык финанславы экспериментын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре. 2026 елга планнар һәм бурычлар» мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итү һәм финанс базарын үстерү эшен, шул исәптән Россия базарының ислам финанслары глобаль системасына кушылуы өчен халыкара ысуллар нигезендә ислам финанславы механизмын кулланып, дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасында партнерлык финанславы принципларына нигезләнеп гамәлгә ашырыла торган проектларга инвестицияләр җәлеп итү эшен дәвам итүне.

3.2. Партнерлык программалары исемлеген киңәйтү, халыкара финанс институтлары һәм оешмалары белән үзара мөнәсәбәтләр өчен институциональ базаны ныгыту мөмкинлеген карауны.

3.3. Партнерлык финанслары өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне глобаль финанс базарының заманча тенденцияләрен исәпкә алып дәвам итүне.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына, партнерлык финанславын үстерүгә кызыксындыру, финанс продуктларының һәм

хезмәтләр күрсәтүнең файдалана алырлык булуын арттыру максатларында, финанс базарын цифрлаштыруны дәвам итүне, алдынгы цифрлы технологияләрне, шул исәптән ясалма интеллект программаларын, эшләү һәм гамәлгә кертү мөмкинлеген карауны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Партнерлык финанслары өлкәсендә квалификацияле белгечләр әзерләүне мониторинглауны һәм тикшереп торуны.

5.2. Инновацияле чишелешләр һәм тәкъдимнәр эшләү өчен партнерлык финанслары өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшчәнлеген үстерүгә булышлык күрсәтүне.

6. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына партнерлык финанславының гамәлдәге чаралары һәм гамәлгә ашырыла торган ислам финанс продуктлары турында халыкка һәм бизнес-бергәлекләргә мәгълүмат бирүдә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты тармак республика башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә, партнерлык финанславы буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру механизмын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында, «Россия Федерациясенең аерым субъектларында партнерлык финанславы буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында махсус җайга салуны билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 417-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында экспериментны гамәлгә ашыруга мониторинг ясауны дәвам итәргә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 577-VII ДС